| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.06.2022 №133пи

Балык Бистәсе штп.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 111п номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 111п номерлы карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына (алга таба-Регламент) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Регламентның 1.5 пунктының 7 абзацын түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

1.1) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, үзгәртеп кору («Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез мөлкәт объектларын өлешле төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш).»;

Регламентның 2.5.1 пунктындагы 6 пунктчасында «блокланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта бер рәттә барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы;» сүзләрен өстәргә;".

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д. Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов